**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

тугызынчы утырыш
**КАРАРЫ**

15 нче май 2026 ел **№ 50** Теләче ав.

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы, «Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33 - ФЗ номерлы Федераль закон, «татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында»Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2026 елның 26 мартындагы 40 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының “Олы Мәтәскә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының “Теләче авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге чиге территориясе составына кертү юлы белән, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының «Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкының Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы составына керүче «Теләче авыл җирлеге» һәм «Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча ризалыгын исәпкә алып, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. «Теләче муниципаль районының Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең һәм Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлегенең территорияләре чикләрен үзгәртү турында һәм «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы

муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын һәм аңа Материалларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы проектын караганда Теләче муниципаль районы Башлыгы Фатхуллин Айрат Гыйлван улын Теләче муниципаль районы Советы вәкиле итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырып бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында халыкка чыгарырга (http://tulachi.tatarstan.ru).

Теләче муниципаль
район Башлыгы

А.Г. Фатхуллин